СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
№1-41

КАРАР
20 май 2019 ел

## Никифорово авыл җирлеге Советының 2015 елның 4 июнендә кабул ителгән 4-47 санлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеш), Никифорово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советы

К А Р А Р  Б И Р Д Е:

1. Никифорово авыл җирлеге Советының 2015 елның 4 июнендә кабул ителгән 4-47 санлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.1 - 3.2. пунктчалары белән тулыландырырга:

«3.1. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балигъ булмаган балалары.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, бер өлеше фатир яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында күрсәтелгән бина яки корылма;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 1 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык төзелеше яисә корылма;

5) гараж яки машина-урын.

Салым ташламасы, салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турындагы гаризаны үз теләге белән тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәр салым түләүче тарафыннан елның 1 ноябренә кадәр салым чоры булып торган салым органына тапшырыла, аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла.

Салым органына сайлап алынган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырган салым чоры булып торган елның 1 ноябреннән соң салым салу объекты үзгәртелеп, күрсәтелгән салым чорында салым ташламасы бирелә торган төгәлләштерелгән белдерү кәгазе тапшырырга хокуклы түгел.

Салым ташламасына, сайланган салым объекты турында хәбәрнамәне салым ташламасына хокукы булган салым түләүче тарафыннан тапшырылмаган очракта салым ташламасы салым суммасының максималь исәпләнгән һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртип нигезендә “Нократ” (“Вятка”) газетасында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) сайтында, урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башлыгы С.Н.Степановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе

Степанов С.Н.